**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

дүртенче утырыш
**КАРАРЫ**

10 декабрь 2025 ел **№ 20** Теләче ав.

Аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда
Теләче муниципаль районының җирле үзидарә
органын билгеләү турында

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2025 елның 28 октябрендәге 124-7 номерлы Татарстан Республикасы законын үтәү максатында, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетын репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән гражданнарны, Татарстан Республикасы территориясендә (репрессияләр кулланылганчы яшәгән урыннарына һәм торак пунктларына) һәм аларның гаилә әгъзалары элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, "Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында" 1991 елның 18 октябрендәге 1761-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә (алга таба текст буенча – дәүләт вәкаләтләре) чикләнмәгән срокка торак урыннар алу хокукына ия булучыларны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпкә алуны алып бару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына 2026 елның 1 гыйнварыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы булган вазыйфаи затларны билгеләргә.
3. Әлеге карар гамәлдә булган законнар нигезендә 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы А.Г. Фатхуллин